ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 13.10.2016 г. г. Казань № 261

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2010 елның 24 декабрендәге «Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазифаларын башкаруга конкурс уздыру турындагы Положениесен раслау турында» 362нче боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы 79-ФЗ санлы Федераль законына яраклаштыру максатыннан чыгып,

әмер бирәм:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2010 елның 24 декабрендәге «Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакансиядәге вазифаларын башкаруга конкурс уздыру турында Положениене раслау турында»гы 362нче боерыгына (алда - Боерык) (Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2011 елның 19 апрелендәге 104нче, 2011 елның 15 сентябрендәге 221нче, 2012 елның 13 июнендәге 168нче, 2013 елның 11 сентябрендәге 255нче, 2013 елның 14 ноябрендәге 348нче, 2014 елның 3 февралендәге 30нчы, 2014 елның 12 маендагы 165нче, 2014 елның 16 июлендәге 213нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1нче кушымтада:

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетында вакансиядәге дәүләт гражданлык вазифаларын башкаруга конкурс уздыру турында Положениегә 2нче кушымтаны әлеге боерык кушымтасына ярашлы рәвештә яңа редакциядә бирергә;

4нче кушымтада:

1.2. нче пункты түбәндәге редакциядә:

«Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакансиядәге вазифасы квалификация таләпләренә ярашмавы сәбәпле һәм шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия

Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурска кертелми.»;

2нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Квалификация таләпләре

2.1. дәүләт хезмәте вазифасын башкару өчен дәүләт хезмәте стажын яисә эш стажын (тәҗрибә) булдыруга квалификация таләпләре:

2.1.1. дәүләт хезмәте вазифалары төп төркеменең барлык категорияләре өчен – специалитет дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белем, магистратура, дәүләт хезмәтендә ике елдан да ким булмаган стаж яисә өч елдан да ким булмаган әзерлек юнәлеше буенча белгечлек стажы булу мәҗбүри;

2.1.2. дәүләт хезмәте вазифаларының әйдәп баручы төркеменең барлык категорияләре – югары белем булу, дәүләт хезмәтендә белгечлек буенча бер елдан да ким булмаган эш стажы яисә ике елдан ким булмаган әзерлек юнәлешендә белгечлек буенча эш стажы булу мәҗбүри;

2.1.3. дәүләт хезмәте вазифаларының өлкән һәм кече төркемен «тәэмин итүче белгечләр» категорияләренә кергән – һөнәри белем булу мәҗбүри.

2.2. Вазифа бурычларын үтәү өчен кирәк булган белемгә һәм белгәннәргә квалификация таләпләре гражданлык хезмәткәренең һөнәри эшчәнлек өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә вазифа регламенты белән билгеләнә. Гражданлык хезмәткәренең шулай ук гражданлык хезмәте вазифасын башкару өчен кирәкле әзерлек юнәлешендәге белгечлеккә квалификация таләпләре дә вазифа регламенты белән каралырга мөмкин.»;

5нче кушымтада:

5нче пунктны төшереп калдырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге 8нче пункт белән тулыландырырга:

«8. 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы 79-ФЗ санлы Федераль Закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты Указы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган башка законнар».

3. Әлеге боерык рәсми бастырылып чыккан көненнән алып 10 көн эчендә үз көченә кертелә.

4. Әлеге боерыкның башкарылуын контрольгә алуны үземдә калдырам.

Рәис вазифасын башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты
боерыгына кушымта

«Татарстан Республикасы
тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 2010 елның 24
декабрендә расланган 362нче
Положениесенә 3нче кушымта

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының гражданлык хезмәте вакансиядәге вазифаларын башкаруга (кадрлар резервына керү) конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан**

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәте вакансиядәге вазифасын башкаруга конкурс уздыра (Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының кадрлар резервына керү өчен конкурс):

____________________________________________________________
(башкарылучы вазифа исеме)

Квалификация таләпләре:

Белгечлек буенча югары белем («Дәүләт һәм муниципаль идарә һәм башкалар»), белгечлек буенча эш стажы – гражданлык хезмәтендә бер елдан да ким булмаган стаж (ике,өч) (башка төрдәге дәүләт хезмәтләре) яисә белгечлек буенча ике елдан да ким (өч) булмаган эш стажы.

Конкурста катнашу өчен бирелә:

1) шәхси гариза,

2) үз кулың белән тутырылган һәм кул куелган анкета,

3) паспорт күчермәсе,

4) нотариаль яисә эш урынында кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче булган очраклардан тыш), яисә гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар,

5) белем һәм квалификация турында документлар күчермәсе, шулай ук гражданинның үз теләге белән өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация бирелүне раслаучы документлар, эш (хезмәт) урыны буенча нотариус һәм кадрлар хезмәте раслаган фәнни исеме һәм фәнни дәрәҗә бирелү турында документлар күчермәләре,

6) гражданинның гражданлык хезмәтенә керү яисә аны үтү өчен каршылык күрсәтә торган авырулары булмавы турында документ,

7) почмаксыз, ялтырамый торган кәгазьгә төшерелгән аклы-каралы ике фотография (4х6);

8) 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы 79-ФЗ санлы Федераль закон, башка федераль законнар, Россия

Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган башка документлар.

Конкурс үткәрелә ___ сәг. «__» ________ 201__ ел.

Конкурс комиссиясенең урнашкан адресы: 420015, Казан, К.Маркс урамы, 66нчы йорт, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты, телефон/факс: 221-82-14, e-mail: kt@tatar.ru.

--------------------------------

<*> Башкарылачак вазифа таләпләренә ярашлы рәвештә»